ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕЕЛГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422640, с. Большая Елга,
ул.Октябрьская, дом 25

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ ЕЛГА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422640, Олы Елга,
Октябрь урамы, 25 нче йорт,

Тел.: (84361) 25265, факс: (84361) 25265, e-mail:Belg.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

Карар № 53

Олы Елга авылы 2024 елның 2 ноябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Башкарма комитетының «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2024 елның 23 сентябрендәге 51 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Олы Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Башкарма комитетының «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2024 елның 23 сентябрендәге 51 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төзелгән гарызнамәне формат-логик тикшерү орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче гарызнамәнең электрон рәвешендәге һәр кырын тутырган вакытта, бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал гарызнамәнең электрон рәвешендәге дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры гарызнамәнең электрон рәвешендәге мәгълүмат җиткерү аша хәбәр ителә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында: Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 йорт; Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 йорт; Сорочьи Горы авылы, Үзәк урам,16А йорт; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге Башлыгы И.Н. Мингалиев